ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясе чикләре һәм аның статусы турында» һәм «Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы законнарына үзгәрешләр кертү хакында» 93-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Казан шәһәр Думасы тарафыннан кертелгән «Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясе чикләре һәм аның статусы турында» һәм «Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы законнарына үзгәрешләр кертү хакында» 93-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 2020 елның 16 июлендә 11.30 сәгатькә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты әлеге закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2020 елның 16 июлендә 12 сәгатькә кадәр эшләп бетерергә һәм

Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2020 елның 16 июле
№ 487-VI ДС